Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

27 январь 2023 ел №1

Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 январендәге 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күму эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы буенча Пенсия фонды бүлегенең Әлмәт районындагы Клиент хезмәте (бүлек хокукларында) 2023 елның 24 январендәге 51-34-09/156 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

Ямаш авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче, 2 нче кушымталар нигезендә Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 7793,48 сум күләмендә 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә һәм билгеләргә.

2. Әлмәт муниципаль районы Ямаш авылы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында» 2022 елның 31 январендәге 1 номерлы карарын үз кечен югалткан дип танырга.

3.. Әлеге карарны Әлмәт районы, Ямаш авылы, Совет урамы, 109а йорты; Зәй-Чишмә авылы, Верхняя урамы, 186 нчы йорт; Березовка авылы, Үзәк урам, 10 нчы йорт , Нолинка авылы, Лесная урамы,3 нчы йорт, Петровка бистәсе, Үзәк урамы, 10 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз кеченә керә һәм 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ямаш авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Е.С.Ларин

Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авылы башкарма комитетының
2023 елның 27 январендәге 1 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 110,41 |
| 2 | Җирләү ечен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4474,78 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 695,19 |
| 4 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2513,10 |
| Барлыгы | | 7793,48 |

Ямаш авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Е.С.Ларин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯМАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Р 06-1386/12
ЯМАШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1644036245
КПП 164401001
ОГРН 1061644002901
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЯМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авылы башкарма комитетының
2023 елның 27 январендәге 1 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 110,41 |
| 2 | Үлгән кешенең гәүдәсен төрү | 2 623,44 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1 851,34 |
| 4 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 695,19 |
| 5 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2513,10 |
| Барлыгы | | 7793,48 |

Ямаш авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Е.С.Ларин